ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз тугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 375-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
3. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзаларын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләрен сайлау турында.
4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары вәкаләтләрен туктату турында.
5. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 369-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 370-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 372-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында» 373-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Удмуртия Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү (тасвирлау) турында 2022 елның 19 декабрендәге 61 номерлы килешүне раслау хакында.

10. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 368-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 367-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 371-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.

13. «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 360-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 366-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 363-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 359-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 246186-8 номерлы федераль закон проекты хакында (салым түләүчеләр – физик затларның салым органнары белән электрон рәвештә хезмәттәшлек итү тәртибен камилләштерү өлешендә).

18. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 200890-8 номерлы федераль закон проекты турында (бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә, рәсми спорт ярышлары җиңүчеләренә аерым хокуклар бирү өлешендә).

19. «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 232776-8 номерлы федераль закон проекты

турында (тимер юлларда урнашкан күперләрне һәм тоннельләрне эксплуатацияләү хакында).

20. Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт иткән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 226676-8 номерлы федераль закон проекты турында (мобилизацияләнгән гражданарга пенсия түләүне дәвам итү турында).

21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.15 статьясының 5 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 253972-8 номерлы федераль закон проекты турында (массакүләм мәгълүмат чараларында утлы корал өчен ату кирәк-яракларын законсыз әзерләү инструкцияләре булган белешмәләр тараткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

22. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{5}$ һәм $39^{10}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

23. 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

24. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 декабре

№ 1750-VI ДС